КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 42

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы, 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы, 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче, 2016 ел, 20 февраль, 103 нче, 2016 ел, 6 август, 536 нчы, 2017 ел, 15 июль, 497 нче, 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче, 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче, 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы, 2018 ел, 12 май, 350 нче, 2018 ел, 18 май, 375 нче, 2018 ел, 24 июль, 592 нче, 2018 ел, 8 сентябрь, 762 нче, 2018 ел, 13 декабрь, 1127 нче, 2019 ел, 19 апрель, 311 нче, 2019 ел, 25 декабрь, 1192 нче, 2020 ел, 11 февраль, 94 нче, 2020 ел, 17 март, 196 нчы, 2020 ел, 27 май, 429 нчы, 2020 ел, 28 июль, 629 нчы, 2020 ел, 2 октябрь, 902 нче, 2020 ел, 6 ноябрь, 1000 нче, 2020 ел, 30 декабрь, 1259 нчы, 2021 ел, 3 февраль, 48 нче, 2021 ел, 06 июнь, 465 нче, 2021 ел, 29 декабрь, 1311 нче, 2022 ел, 17 сентябрь, 1014 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1460 нчы, 2023 ел, 10 июнь, 709 нчы, 2023 ел, 31 июль, 910 нчы, 2023 ел, 23 август, 1006 нчы, 2023 ел, 19 сентябрь, 1155 нче, 2023 ел, 29 декабрь, 1755 нче, 2024 ел, 1 июль, 484 нче, 2024 ел, 26 сентябрь, 834 нче, 2024 ел, 6 декабрь, 1110 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

беренче абзацта «947,5» һәм «20 075,576» саннарын тиешенчә «949,5» һәм «20 149,5» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «126» һәм «3 134,722» саннарын тиешенчә «128» һәм «3 208,646» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «өч» сүзен «дүрт» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 4.1.495 пункт өстәргә:


«$4.1.49^5$. Түли алмау (банкротлык) мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 30 гыйнвар, 42 нче карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы структурасы




---